Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка З.Ф. Калоян шикаятенә бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацының, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2022 елның 8 апреле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацының, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка З.Ф. Калоян шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.С. Мусин мәгълүматын, яклар — гражданка З.Ф. Калоян, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенең юридик бүлеге башлыгы Р.Н. Сафин аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка З.Ф. Калоян Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән вакытта гамәлдә булган редакциясендә, 1.6 пунктындагы икенче абзацы, 2.7 һәм 2.8 пунктлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге Административ регламентның 1.6 пунктындагы икенче абзацы нигезендә гариза бирүче — яшәү урыны буенча Казан шәһәрендә теркәлгән, социаль наем шартнамәсе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләнең барлык әгъзаларының ризалыгы белән Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән район(-нар) администрациясенә мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданины.

Күрсәтелгән Административ регламентның 2.7 һәм 2.8 пунктлары Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеген тиешенчә билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче яшәү урыны буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясенә үзен аз керемле дип тану һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма югарыда күрсәтелгән районнар территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән булу сәбәпле, аңа мондый исәпкә алу өчен документларын кабул итүдән баш тартканнар.

Шуның белән бергә гражданка З.Ф. Калоян объектив сәбәпләр аркасында фактта үзе яши торган торак урында аның теркәлү мөмкинлеге булмавын билгеләп үтә.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба — Торак кодексы) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) нигезендә яшәү урыны буенча теркәлү мәҗбүри булуы гражданны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу шарты булып тормый.

Гражданка З.Ф. Калоян раслаганча, аның яшәү урыны буенча теркәлү булмауга бәйле социаль наем шартнамәсе буенча торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә кую турындагы гаризасын кабул итүдән баш тарту югарыда күрсәтелгән Административ регламентның карала торган муниципаль хезмәт

яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр булган очракта күрсәтелергә тиешлеген күз алдында тоткан дәгъва белдерелә торган нигезләмәләренә нигезләнгән. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче санаганча, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрне билгеләгән әлеге Административ регламентның 2.7 пункты һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрне беркетүче карала торган Административ регламентның 2.8 пункты гражданны торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә куюдан баш тарту мәсьәләсе җайга салынган Торак кодексының төп нормалары белән килешмиләр (54 статья), ә мондый исәпкә кую өчен мөрәҗәгать иткән гражданның гаризасын кабул итүдән баш тарту мөмкинлеге каралмаган.

Гражданка З.Ф. Калоян шикаяте Татарстан Республикасы Конституция судының 2020 елның 18 декабрендәге 41-О номерлы билгеләмәсе белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.6 пунктындагы икенче абзацының, 2.7 һәм 2.8 пунктларының конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алынган иде.

Эшне суд утырышында карый башлаганда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 2 февралендәге 330 номерлы карары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карарына үзгәрешләр кертелгән, алар нигезендә шикаять белдерелә торган Административ регламент яңа редакциядә бәян ителгән. Аерым алганда, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Административ регламентның элек 1.6 пунктының икенче абзацында, 2.7 һәм 2.8 пунктларында булган нигезләмәләре Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының (алга таба шулай ук —

Административ регламент) 1.5 пунктындагы икенче абзацында, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларында үз чагылышларын тапкан. Шулай, Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацы гариза бирүче — Казан шәһәрендә яшәүче, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләнең барлык әгъзалары ризалыгы белән яшәү урыны буенча район(-нар) администрациясенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданины, дип билгели; Административ регламентның 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктлары Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт (алга таба шулай ук — муниципаль хезмәт) күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр исемлеген һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр исемлеген тиешенчә күздә тота.

Шуның белән бергә гражданка З.Ф. Калоян Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацы белән билгеләнгән хокукый җайга салу, кертелгән үзгәрешләргә карамастан, аны кулланунының муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче үзенең яшәү урынын яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә раслау шарты белән гамәлгә ашырылу практикасын юкка чыгармый, дип күрсәтә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, китерелгән үзгәрешләр шулай ук тиешле гаризаны һәм кушымта итеп бирелгән документларны кабул итүне кире кагу өчен дә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен дә нигезләрнең тулы исемлеген билгели торган хокукый җайга салуның билгесезлеген юкка чыгармый.

Шуңа бәйле рәвештә суд утырышы барышында гражданка З.Ф. Калоян үз таләпләрен төгәлләштерде, алар нигезендә шикаятьтә бәян ителгән нигезләр буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацын, 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларын Татарстан

Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан

Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентындагы 1.5 пунктының икенче абзацы, анда муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче Казан шәһәрендә яшәүче граждан булуын билгеләп, күрсәтелгән нормага хокук куллану практикасы белән бирелгән мәгънәсе буенча мөрәҗәгать итүченең Казан шәһәрендә яшәү факты аның яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә раслануына кайтып калуына юл куйган дәрәҗәдә;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктлары, аларда беркетелгән нормаларны бәян итү рәвешләренең охшашлыгы гражданга муниципаль хезмәт күрсәтүдән нинди нигезләр буенча баш тартырга мөмкин булуы турындагы мәсьәләдә билгесезлек тудырганга күрә.

2. Элегрәк Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан кабул ителгән карарларда Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә карата нәтиҗә чыгарылган (2020 елның 16 июнендәге 91-П номерлы һәм 2021 елның 2 мартындагы 96-П номерлы карарлар).

Татарстан Республикасы Конституция судының аларда чагылдырылган хокукый позициясеннән күренгәнчә, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар нигезендә җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә; җирле үзидарә органнары муниципаль милеккә мөстәкыйль идарә итәләр, җирле бюджетны төзиләр, раслыйлар һәм үтиләр, җирле салымнар һәм җыемнар билгелиләр, җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыралар, шулай ук җирле әһәмияткә ия бүтән мәсьәләләрне хәл итәләр.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясенең 7 һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Бу дәүләттә закон чыгару һәм башкарма хакимият органнарының гражданнар тарафыннан торакка хокукын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хокукый, оештыру һәм икътисадый шартлар тәэмин итү бурычы бар дигәнне аңлата.

Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыру өчен үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак урыннарны яллау шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак урыннар бирәләр (3 пункт).

3.1. Торак кодексы гражданнарны социаль яллау шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпкә алып бару тәртибен билгеләүне торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертә (13 статьяның 7 пункты).

Әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе билгеләнгән.

Торак кодексы нигезендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге гражданнарның үз яшәү урыннары буенча күрсәтелгән органга тапшырылган яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән үзара хезмәттәшлек турында килешү буенча күпфункцияле үзәк аша тапшырылган гаризалар нигезендә гамәлгә ашырыла; законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гражданнар үзләренең яшәү урыннарыннан тыш та исәпкә алу турында гариза бирә алалар (52 статьяның 3 өлеше). 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлеше шундый ук нигезләмәләрне беркетә.

Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу муниципаль хезмәт булып тора һәм аны күрсәтү «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба — 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 12 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ регламент буенча гамәлгә ашырылырга тиеш. Шулай, Казан шәһәрендә гражданнарны мондый исәпкә алу әлеге эштә каралган Административ регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

Административ регламентның шикаять белдерелә торган 1.5 пункты гариза бирүче — Казан шәһәрендә яшәүче, торак шартларын яхшыртуга

мохтаҗ гаиләнең барлык әгъзалары ризалыгы белән яшәү урыны буенча район(-нар) администрациясенә Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясе гражданины булуын билгели.

Дәгъва белдерелә торган норманың сүзгә-сүз эчтәлеген анализлаудан күренгәнчә, карала торган эшкә карата мөрәҗәгать итүченең күрсәтелгән муниципаль хезмәт алуга хокукын билгеләү өчен кирәкле шартлар исәбенә аның Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәве керә. Аталган нигезләмәне гамәлгә ашыру, хокук куллану практикасы күрсәткәнчә, мөрәҗәгать итүченең Казан шәһәрендә яшәү факты аның яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләргә туры килергә тиешлегенә кайтып кала.

Шикаять белдерелә торган норманың конституциячеллеген бәяләү «яшәү урыны» төшенчәсен ачыклаудан башка мөмкин түгел. Шулай итеп, Россия Федерациясе Конституциясенең 27 статьясы (1 өлеш) нигезендә Россия Федерациясе территориясендә законлы төстә яшәүче һәркем ирекле рәвештә күчеп йөрүгә, тору һәм яшәү урынын сайлап алуга хокуклы. Мәгънәсе буенча шундый ук нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 39 статьясында да бар.

Югарыда күрсәтелгән конституциячел нигезләмәләр Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясында һәм «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» 1993 елның 25 июнендәге 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба — 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) 2 һәм 3 статьяларында үсеш алган, аларда гражданның яшәү урыны буларак ул Россия Федерациясе законнары белән каралган нигезләрдә даими яки күпчелек рәвештә яши торган һәм яшәү урыны буенча теркәлгән торак урын билгеләнгән. Әлеге Россия Федерациясе Законының 2 статьясындагы 4 абзацы нигезендә Россия Федерациясе гражданының яшәү урыны буенча теркәлүе Россия Федерациясе гражданының

яшәү урыны турында һәм аның әлеге яшәү урынында булуы хакында мәгълүматны теркәү исәбе органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәү булып тора. Шул ук вакытта 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 3 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Россия Федерациясе гражданнары тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе чикләрендә теркәлергә тиеш; теркәлү яисә аның булмавы гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, Россия Федерациясе субъектлары конституцияләрендә (уставларында) һәм законнарында каралган хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруны чикләргә нигез яисә аның шарты булып тора алмый.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән кертелгән Россия Федерациясе гражданнарын теркәү, аның конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча, хәбәр итү характерына ия булган һәм гражданның тору яки яшәү урыны буенча булу фактын чагылдыра торган Россия Федерациясе чикләрендә гражданнарны исәпкә алуның федераль законда каралган ысулы гына булып тора; теркәү исәбе органнары гражданның тору һәм яшәү урынын сайлаганда ирекле ихтыяр белдерү актын расларга гына вәкаләтле; нәкъ менә шуңа күрә теркәү исәбе рөхсәт характерында була алмый һәм гражданның тору һәм яшәү урынын сайлау конституциячел хокукын чикләүгә китерергә тиеш түгел (1995 елның 24 ноябрендәге 14-П номерлы, 1996 елның 4 апрелендәге 9-П номерлы, 1998 елның 15 гыйнварындагы 2-П номерлы, 1998 елның 2 февралендәге 4-П номерлы, 2021 елның 30 июнендәге 31-П номерлы һ.б. карарлар).

Россия Федерациясе Югары Суды шулай ук үзенең хокук куллану практикасында игътибарны шуңа юнәлдергән: Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясы һәм 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 2 һәм 3 статьялары эчтәлегеннән теркәлүнең «яшәү урыны» төшенчәсенә туры килмәве һәм үзеннән-үзе гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясендә, Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясе составындагы республикаларның конституцияләре һәм законнарында каралган

хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру шарты булып тора алмавы аңлашыла (Россия Федерациясе Югары Суды Президиумы тарафыннан 2016 елның 20 декабрендә расланган Россия Федерациясе Югары Судының суд практикасына күзәтүенең (№ 4, 2016) IV бүлегендәге 12 пункты).

Гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар дип тану тәртибен регламентлаштыруга карата Россия Федерациясе Конституция Суды шулай ук түбәндәгеләрне билгеләп үтә: хокуктан явыз ният белән файдалануны булдырмау максатларында закон чыгаручы норматив хокукый актларда аерым оештыру-исәпкә алу кагыйдәләрен күздә тота ала; гражданның яшәү урыны буенча теркәлүе булуы турында шартны кертү — чөнки ул торакны гадел бүлүне тәэмин итүгә, торак шартларын яхшырту буенча исәпкә кую турында гариза белән мөрәҗәгать итүче гражданнар һәм муниципаль торак белән идарә итү органнары ягыннан мөмкин булган явыз ният белән файдалануны булдырмый калуга, шулай ук торак фонды милекчеләренең, башка гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән — Россия Федерациясе Конституциясенең 17, 19, 27 һәм 40 статьялары күрсәтмәләре белән туры килми торган буларак карала алмый; шул ук вакытта гражданның яшәү урыны, гомуми юрисдикция суды тарафыннан теркәү төре белән мәҗбүри бәйле булмаган юридик фактлар нигезендә билгеләнергә мөмкин (2011 елның 30 июнендәге 13-П номерлы Карар; 2000 елның 13 июлендәге 185-О номерлы, 2000 елның 5 октябрендәге 199-О номерлы, 2002 елның 9 апрелендәге 123-О номерлы билгеләмәләр).

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә кую өчен кирәкле шарт буларак, яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән беррәттән, гражданның үзе тарафыннан тапшырылган тиешле суд карары белән расланган булырга мөмкин. Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацында кулланылган «яшәүче» төшенчәсе «яшәү урыны» төшенчәсен билгели торган граждан һәрвакытта да яшәү урыны буенча фактта үзе яши торган торак урында теркәлмәгән булырга

мөмкинлеген күз алдында торган югарыда китерелгән конституциячел күрсәтмәләр һәм граждан законнары нигезләмәләре призмасы аша хокук куллану практикасында аңлашылырга һәм кулланылырга тиеш.

Мондый алым анда булган норматив нигезләмәләрнең, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нигезләрен һәм тәртибен, димәк аларны куллану практикасын да ачыклый торган нигезләмәләрнең мәгънәсен аңлатып, Административ регламентның нигезен тәшкил итәргә тиеш.

Шуның белән Татарстан Республикасы Конституция суды Административ регламентның 1.5 пунктының икенче абзацы, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүче Казан шәһәрендә яшәүче граждан булуын билгеләп, үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле шарт булып әлеге муниципаль берәмлек территориясендә яшәү факты ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән расланырга тиеш булган яисә аны тапшыру бурычы гражданга йөкләнергә тиеш булган тиешле суд карары белән расланырга тиеш булуын күздә тоткан дәрәҗәдә һәм шикаять белдерелә торган норманың Казан шәһәрендә мөрәҗәгать итүченең яшәү фактын бары тик яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә раслануга кайтып кала торган мондый кулланылышына юл куймый дип саный һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү механизмын әлеге муниципаль хезмәтне алуга дәгъва кылучы граждан тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенә, гражданның Казан шәһәре территориясендә яшәү фактын раслаучы суд карарын тапшыру мөмкинлеген күрсәтеп, үзгәрешләр кертү юлы белән камилләштерүгә комачауламый. Моннан тыш, Татарстан Республикасы

Конституция суды Административ регламент нормаларына, шул исәптән гражданны һәм аның гаиләсен торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу турында гариза формасын раслаучы Административ регламентның 3 кушымтасына төгәллекләр кертү максатка ярашлы дип саный, аның эчтәлегеннән аңлашылганча, «яшәү урыны» төшенчәсен аңлау ул бары тик яшәү урыны буенча теркәү исәбе турындагы белешмәләр белән генә расланырга мөмкин булуына кайтып кала. Бу Административ регламентның 1.5 пунктындагы икенче абзацын һәм, димәк, аның белән системалы бердәмлектә булган Административ регламентның башка нормаларын куллануга бертөрле якын килүне тәэмин итәр иде.

3.2. Торак кодексының 54 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алудан баш тарту турында җирле үзидарә органнары тарафыннан карар чыгару өчен нигезләр исемлеге беркетелгән. Әлеге Кодексның 52 статьясындагы 4 өлешендә каралган гражданның торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын раслаучы документлар, исәпкә алуны гамәлгә ашыручы орган тарафыннан ведомствоара мөрәҗәгатьләр нигезендә алына торган документлардан тыш, мөрәҗәгать итүченең үзе тарафыннан тапшырылмаган очракта мондый баш тарту мөмкин була (1 пункт); әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың ведомствоара мөрәҗәгатькә җавабы Торак кодексының 52 статьясындагы 4 өлеше нигезендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавын раслый, моңа мондый соратып алына торган документ яисә мәгълүматның югарыда күрсәтелгән органнар яисә оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗ буларак исәптә тору хокукын раслаган очраклар керми (1.1 пункт); тиешле гражданнарның торак урыннарга мохтаҗлар исәбендә тору хокукын расламый торган документлар тапшырылганда (2 пункт); граждан торак урынына мохтаж

буларак исәптә тору хокукын алу нияте белән гамәлләр кылган көннән биш ел вакыт узмаган булса (3 пункт). Шундый ук нигезләмәләр 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 1 өлешендә беркетелгән.

Торак кодексының әлеге нормалары система барлыкка китерүче булып торалар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу мәсьәләләрен алга таба җайга салу өчен гомуми параметрлар билгелиләр. Гражданнарны мондый исәпкә алу, үз чиратында, 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарга хезмәт күрсәтү процедурасын Торак кодексында, шул исәптән аның 54 статьясында билгеләнгән хокукый җайга салудан килеп чыга торган фикер йөртү чикләрендә тәгәлләштерергә һәм структуралаштырырга тиешле административ регламентлар кысаларында күрсәтелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүдән гыйбарәт. Торак кодексының әлеге статьясын дәвам итеп һәм, муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпне күздә тоткан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясының 2 өлешендәге 2 пунктының һәм 14 статьясының 1 өлешендәге 7 һәм 8 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре таләпләрен үтәү йөзеннән, әлеге эштә карала торган Административ регламент белән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу (документларны асылы буенча карап тикшермичә кире кайтару) өчен нигезләрнең (2.7.1 пункт) һәм әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләрнең (2.8.2 пункт) тулы исемлеге билгеләнгән.

Административ регламентның 2.7.1 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны вәкаләтләренә муниципаль хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага бирү (1 пунктча); муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза формасында булган мәҗбүри тутырылырга тиешле юлларны тулысынча тутырмау (дөрес итеп тутырмау, хаталы итеп тутыру) (2 пунктча); документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру

(3 пунктча); муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән вакытка тапшырылган документларның (шәхесне таныклый торган документ; муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ) гамәлдән чыккан булуы (4 пунктча); тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр һәм (яки) каршылыклы мәгълүматлар, текстта Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган бозып язулар һәм төзәтүләр, аларның эчтәлеген төгәл аңларга мөмкинлек бирми торган җитди зыяннар булу (5 пунктча); муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон формада биргәндә билгеләнгән таләпләрне үтәмәү (6 пунктча); электрон формада тапшырылган документларда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен бирелә торган документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланулар булу (7 пунктча); гаризаны гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклау вәкаләте булмаган зат бирү (8 пунктча).

Административ регламентның 2.8.2 пункты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен түбәндәге очраклар нигез булып тора: гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины булып тормый (әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса) (1 пунктча); әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз теләге белән тапшырылмаган булса, дәүләт органының, җирле үзидарә органының, оешманың ведомствоара мөрәҗәгатькә җавабы гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавын таныклый (мондый органнар яисә оешмалар карамагында әлеге соратып алына торган документ яисә мәгълүмат булмау тиешле гражданнарның торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын раслый торган очраклардан тыш) (2 пунктча); 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә гражданинны аз керемле дип тану өчен нигезләр булмау (3 пунктча); гражданнарның торак

урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын расламаган документлар тапшырылган һәм (яисә) мөрәҗәгать буенча алынган (4 пунктча); гражданнар тарафыннан аларны торак урыннарга мохтаҗ дип танырга мөмкинлек биргән гамәлләр кылынганнан соң, законнарда билгеләнгән вакыт узмаган (5 пунктча); гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган яки тапшырылган гаризада һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар (6 пунктча).

Административ регламентның дәгъва белдерелә торган 2.8.2 пунктының сүзгә-сүз эчтәлеген анализлау күрсәткәнчә, анда билгеләнгән хокукый нормалар үзләренең хокукый мәгънәсе буенча федераль һәм республика законнары нигезендә билгеләнгән логикага җавап бирәләр һәм гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алыну хокукын гамәлгә ашыруда нигезсез чикләүләрне беркетмиләр. Шул ук вакытта аталган хокукый җайга салуга Административ регламентның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеген беркетүче 2.7.1 пункты нигезләмәләре билгесезлек кертә, чөнки анда беркетелгән нигезләмәләрнең эчтәлеген анализлаудан күренгәнчә, граждан тарафыннан тапшырыла торган документларның анда билгеләнгән бәяләү критерийлары, асылда, гражданның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак аны исәпкә куюда хокуклылыгын билгеләү максатларында кулланыла торган мондый исәпкә куелудан баш тарту турында карар кабул итү стадиясендә гамәлгә ашырыла торган бәяләү критерийлары белән охшаш.

Административ регламентның 2.7.1 пунктына хокук куллану практикасы белән бирелә торган мәгънәсе муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен аның тарафыннан билгеләнгән нигезләрнең исемлеген киңәйтеп аңлатуны рөхсәт итә һәм фактта асылы буенча бирелгән документларны кабул итү стадиясендә бәяләүгә китерә, бу асылда алдан тикшерү булып тора, аның нәтиҗәләре буенча документларны кабул итү кире кагылырга мөмкин. Шул ук вакытта мондый җайга салу Торак кодексының 54 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләре һәм аның белән үзара

бәйле мондый бәяләү гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куюны кире кагу турында карар кабул итү стадиясендә, ягъни гаризаны һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларны асылы буенча караганда булырга мөмкинлеген күздә тоткан 52 статьясындагы 4 өлеше нигезләмәләре белән каршылыкка керә.

Шуның белән бергә Административ регламентның 2.7.1 пунктының конституциячеллеген бәяләү аталган регламентның 2.7 пунктына мөрәҗәгать итмичә мөмкин түгел, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу һәм документларны асылы буенча карап тикшермичә кире кайтару арасында мәгънәдәшлек бар. Бу күрсәтелгән документларны кабул итү процедурасы мөрәҗәгать итүченең шәхесен һәм вәкаләтләрен билгеләүгә, гаризасын тиешенчә рәсмиләштерү күзлегеннән чыгып тикшерүгә, тапшырылган документларны гаризага кушымталар итеп күрсәтелгән документлар белән чагыштыруга һәм аларның җиңел укылышына йогынты ясый торган, аларның дөрес булмавы ихтималын тудыра торган техник зарарлануларны тикшерүгә кайтып калырга тиеш дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Административ регламентның дәгъва белдерелә торган 2.7.1 пунктының нәкъ менә шундый хокукый мәгънәсе гражданны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куюда аның хокуклылыгын билгеләү һәм, димәк, тәкъдим ителгән документларны асылы буенча карау бары тик гражданны исәпкә алу (исәпкә алуны кире кагу) турында карар кабул иткәндә генә мөмкин, бу Административ регламент нормалары системасында алдан тикшерү үткәрүне билгели торган — документларны асылы буенча бәяләүгә юл куймый торган формаль билгеләр буенча документларны карауны билгеләгән нигезләмәләрне беркетү кирәклеген нигезләүне күз алдында тоткан Торак кодексының 52 статьясындагы 4 өлешенең һәм 54 статьясындагы 1 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләренең турыдан-туры гамәле белән алдан билгеләнгән. Шикаять белдерелә торган норманы аңлауда һәм аңлатуда бары тик мондый алым гына җирле үзидарә органнарының гражданнар белән конструктив

бәйләнешен тулысынча тәэмин итәчәк, гариза биргәндә граждан тарафыннан җибәрелгән асылда техник хаталар (җитешсезлекләр) тиешле исәпкә куюны кире кагуга китерергә мөмкин булган хәлләрне юкка чыгарачак, шулай ук гражданны торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү процессы сузылуны булдырмый калачак.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Административ регламентның 2.7.1 пунктында каралган җайга салу, анда беркетелгән нигезләмәләрне бәян итү формасы күзлегеннән, югарыда күрсәтелгән әлеге норманың максатчан билгеләнешен төрле мәгънәдә аңлауны һәм муниципаль хезмәт алганда гражданнарның хокукларын акланмаган чикләүне бетерү максатларында үзгәртелергә тиешлегенә басым ясарга кирәк дип саный.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларында билгеләнгән хокукый җайга салу, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуның оештыру-процедура механизмы элементы буларак, торак законнарының махсус нормаларында салынган төп принципларны эзлекле рәвештә гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацын, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктындагы икенче абзацының әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе һәркем өчен мәҗбүри, бу аның хокук куллану практикасында теләсә нинди башкача аңлатылуына юл калдырмый.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларын, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.7.1 һәм 2.8.2 пунктларының әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе һәркем өчен мәҗбүри, бу аларны хокук куллану практикасында теләсә нинди башкача аңлатуга юл калдырмый.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән

үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 105-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**